Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XIII-2**

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 30 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге XXVI-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш эшләрен җайга салу тәртибен камилләштерү максатларында, Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексының 8 маддәсендәге 1 өлешенә, 32, 33 маддәләренә, Россия Федерациясе Җир кодексына, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына ярашлы рәвештә, Олы Елга авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык (гавами) тыңлаулар нәтиҗәләре турында 2021 елның 23 августындагы 1 нче номерлы бәяләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге XXVI-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр), “Ж1. Шәхси торак төзелеше зонасы” бүлеге таблицасын түбәндәге яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

| Параметрларның төрләре һәм үлчәү берәмлекләре | Күчемсез мөлкәтне файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрларның кыйммәтләре | |
|---|---|---|
| | Аерым торучы бер гаиләлек йорт | Блокланган йортта бер гаиләгә торак |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | берәмлеге |
| **Җир кишәрлекләренең иң чик параметрлары** | | | |
| Минималь мәйдан | кв.м | 1000 | 1000 |
| Максималь мәйдан | кв.м | 2500 | - |
| Урам (юл йөрү) фронты буйлап минималь киңлек | м | 12 | 6 |
| **Кишәрлекләр чикләрендә рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары** | | | |
| Кишәрлек төзелешенең максималь проценты | % | 40,5 | 55 |
| Кишәрлекнең алгы чигеннән төзелмәләрнең минималь чигенеше (калган аралыгы) (төзелешне җайга салу линиясе белән башка күрсәткеч билгеләнмәгән очракларда) | м | 3 | 3 |
| Кишәрлекнең ян чикләреннән төзелмәләрнең минималь чигенеше (калган аралыгы) | м | а) 1- брандмауэр (янгынга чыдам) дивар мәҗбүри булганда;<br>б) 3 – башка очракларда | а) 0 - күрше блокларга кушылган очракларда;<br>б) 3 - башка очракларда |
| Кишәрлекнең алгы чигеннән төзелмәләрнең минималь чигенеше (калган аралыгы) (төзелеш эшләрен җайга салу линиясе белән башкасы билгеләнмәгән булса) | м | 3 | 3 |
| Төп төзелмә катларының иң чик саны (мансард катын да кертеп) | кат | 3 | 3 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Төзелмәләрнең максималь биеклеге | м | 10 | 10 |
| Ярдәмче төзелмәләр катларының иң чик саны | кат | 1 | 1 |
| Ярдәмче төзелмәләрнең иң чик биеклеге (яссы түбә/скат түбә) | м | 3,5/4,5 | 3,5/4,5 |
| Җир кишәрлекләре киртәләренең максималь биеклеге | м | 2* | 2* |

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге XXVI-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Елга авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренең кушымтадагы редакциядә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге территориясеннән файдалануның шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына һәм махсус шартлары булган картасына үзгәрешләр кертергә һәм расларга.

2.1. кадастр номеры 16:34:050702:5, мәйданы 4 873 кв.м булган, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Казань-Оренбург трассасының 74 км ы адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген үз эченә алган территориягә карата транспорт инфраструктурасы зонасын билгеләү өлешендә (ИТ2).

2.2. кадастр номеры 16:34:050702:6, мәйданы 2 743 кв.м булган, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Казань-Оренбург трассасының 74 км ы адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген үз эченә алган территориягә карата транспорт инфраструктурасы зонасын билгеләү өлешендә (ИТ2).

2.3. кадастр номеры 16:34:050702:119, мәйданы 2 400 кв.м булган, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Елга авыл җирлеге, Казань-Оренбург автоюлының 74 км ы адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген үз эченә алган территориягә карата транспорт инфраструктурасы зонасын билгеләү өлешендә (ИТ2).

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам, 16А йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов